# Тәнкыйди фикерләүне үстерү алымнары



1 Идеяләр
2 Инсерт кәрзинә
3 Синквейн
4 Алты эшләпә.....

# «Идеяләр кәрзине» ысулы




**Бу ысул укучыларның дәрес темасы белән ни дәрәҗәдә хәбәрдар булуын күрсәтә.**

# «Кластер төзү» ысулы

***Кластер тексттагы фикерләрне, төшенчәләрне аерып алу һәм аларның мәгънәви бәйләнешен график сурәттә күрсәтү дигән сүзне аңлата***




Татарстан



# Инсерт ысулы

Бу ысулны икенче төрле “текстны тамгалау” дип атыйлар. Материалны уку барышында укучы текст кырыена( поляга) тамга, билге куеп бара. Укытучы билгеләр ярдәмендә уку эшчәнлеген оештыра




# Инсерт таблицасы

| V | + | - | ? |
|---|---|---|---|
| Мин моны белә идем | Бу миңа өр-яңа | Бу минем фикергә каршы килә | Бу турыда күбрәк белергә телим |



# “Синквейн язу”ысулы

*“Синквейн” сүзе французча шигырь дигәнне аңлата. Бу билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнгән иҗади эш формасы. Ул кыска төшенчәләр кулланып, укылган материал буенча нәтиҗә (резюме) чыгарырга ярдәм итә .*



# “Синквейн язу”ысулы

**1 нче юл:** Теманы ачыклаучы сүз, исем.

**2 нче юл:** Темага туры килүче ике сыйфат.

**3 нче юл:** Темага хас булган өч фигыль.


**4 нче юл:** Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә.

**5 нче юл:** Укучының темага карата үз фикерен чагылдыручы бер сүз( нәтиҗә)



# “Синквейн язу” ысулы

***Яр Чаллы***
***Заманча, алдынгы.***
***Яши, үсә, яңара.***
***Минем туган шәһәрем.***
***Татарстан.***



# Алты эшләпә» ысулы

**Бу ысул ярдәмендә фикерләүнең алты ысулын күрсәтергә була. Укучылар алты төркемгә бүленә. Аларның һәрберсе төрле төстәге эшләпә ала. Нинди төстәге эшләпә алуга карап, укучылар укылган әсәр буенча геройларга карата үз фикерләрен белдерәләр.**





Укучы бары тик фактлар белән генә эшли. Әсәрнең төп вакыйгаларын санап чыга, нинди персонажлар булуын әйтә, аларга к…ча бәя бирә.



Уңай фикерләр генә әйтелә. Һәр вакыйганың, образның позитив яклары турында сөйләнә.



Бу эшләпәне алган төркем нәкъ киресен, ягъни …а- вакыйгаларның тискәре якларын гына …әр.

Килеп чыккан проблемаларга бәя бирәләр.





Бу эшләпә эмоциональ фикерләүне таләп итә. Тексттан хис – кичерешләргә бай урыннарны туплый.



Бу төркем үзләренең башка төркемнәрдән булулары белән аерылып торалар.



Бу эшләпә ияләре әсәр буенча фәлсәфи фикер йөртә, йомгак ясый, нәтиҗәләр чыгара. Нәкъ менә алар башкаларның фикерләрен игътибар белән тыңларга тиешләр, чөнки алар алдында иң җаваплы бурыч – барлык төркемнәрнең җавапларын берләштереп, нәтиҗә чыгару тора.



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

